| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.09.2022 Казан ш. № 880

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар ташлау нәтиҗәсендә пычранган торак пунктлардан күченеп киткән гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 19 июлендәге 575 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының аерым боерыкларын һәм боерыкларының аерым нигезләмәләрен көчен югалткан дип тану турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар ташлау нәтиҗәсендә пычранган торак пунктлардан күченеп киткән гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 19 июлендәге 575 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.07.2016 №443, 08.06.2017 №348, 07.05.2018 №357, 19.09.2018 №887, 14.11.2019 №1015, 14.07.2020 №518,

09.10.2022 №715, 20.12.2021 №945 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 19 июлендәге 576 номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 7 июнендәге 317 номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелгән үзгәрешләрнең 18 пунктын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 19 июлендәге 576 номерлы боерыгы белән расланган 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 26 июлендәге 442 номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 8 июнендәге 348 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрнең 1 пунктындагы уникенче абзацын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 7 маендагы 357 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрнең 1 пунктындагы өченче абзацын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 сентябрендәге 887 номерлы боерыгы белән расланган Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрнең 3 пунктын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү

турында» 2019 елның 26 июлендәге 580 номерлы боерыгы белән расланган Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрнең 4 пунктын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 15 ноябрендәге 1031 номерлы боерыгы белән расланган Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрнең 4 пунктын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 14 июлендәге 518 номерлы боерыгы белән расланган Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрнең 4 пунктын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 9 октябрендәге 715 номерлы боерыгы белән расланган Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрнең 4 пунктын;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм радиоактив калдыкларның Тичә елгасына элэгү нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2012 елның 19 июлендәге 576 номерлы боерыгы белән расланган 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм радиоактив калдыкларның Тичә елгасына элэгү нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 20 маендагы 327 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгын;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 20 декабрендәге 945 номерлы боерыгы белән расланган Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрнең 1 пунктын.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2022 елның 21
сентябрендәге 880 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар ташлау нәтиҗәсендә пычранган торак пунктлардан күченеп киткән гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 19 июлендәге 575 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын (алга таба – Административ регламент) расларга.»;

әлеге боерык белән расланган 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар ташлау нәтиҗәсендә пычранган торак пунктлардан күченеп киткән гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»;

1 бүлектә:

1.1 һәм 1.2 пунктларны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.1. 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган

гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр:

а) гражданнар (шул исәптән вакытлыча җибәрелгән яки командировкага җибәрелгән), махсус җыеннарга чакырылган хәрби хезмәткәрләрне һәм хәрби бурычлыларны да исәпкә алып, эчке эшләр органнарының, дәүләт куркынычсызлыгы органнарының, гражданнар оборонасы органнарының җитәкчелек һәм гади составы затлары:

1957 елның 29 сентябреннән 1961 елның 31 декабренә кадәрге чорда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү эшләрендә турыдан-туры катнашкан затлар;

1949 елның 1 гыйнварыннан 1962 елның 31 декабренә кадәрге чорда Тичә елгасы буендагы радиоактив пычранган территорияләрне саклау чараларын үткәрү һәм тернәкләндерү эшләре белән мәшгуль булган затлар;

2) «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 175-ФЗ номерлы федераль закон) 1 статьясының беренче өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында, 2 һәм 3 статьяларында күрсәтелгән гражданнар арасыннан тукландыручыларын югалткан гаиләләр;

в) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиоактив пычрануга дучар булган торак пунктларыннан эвакуацияләнгән (күчерелгән), шулай ук ирекле рәвештә чыгып киткән (шул исәптән эвакуацияләү (күчерү) өлешчә башкарылган торак пунктлары чикләрендә эвакуацияләнгән (күчерелгән)) гражданнар, балаларны, шулай ук 1957 елда радиоактив пычрану зонасыннан эвакуацияләнгән хәрби хезмәткәрләр, хәрби частьләрнең ирекле ялланган составы һәм махсус контингент. Ирекле рәвештә чыгып киткән гражданнарга 1957 елның 29 сентябреннән башлап 1960 елның 31 декабренә кадәрге чорда 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт аркасында радиоактив пычрануга дучар булган торак пунктларыннан чыгып киткән, шулай ук 1949 елдан башлап 1962 ел тәмамланганчыга кадәр Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиоактив пычрануга дучар булган торак пунктларыннан чыгып киткән (шул исәптән күчерү эшләре өлешчә алып барылган торак пунктлары чикләрендә күченгән) гражданнар керә;

г) 1949-1956 елларда Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү нәтиҗәсендә радиоактив пычрануга дучар булган торак пунктларында яшәгән һәм нурланышның 7 сЗв (бэр) артык, ләкин иң күбе 35 сЗв (бэр) дәрәҗәсендә яисә 36 сЗв (бэр) тупланган нәтиҗәле дозасын алган гражданнар;

д) 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына ташланган радиоактив калдыклар нәтиҗәсендә радиоактив пычрануга дучар булган, еллык уртача эффектив нурланыш дәрәҗәсе хәзерге вакытта 1 мЗв (0,1 бэр) артык булган (әлеге җирлек буенча табигый радиация фоны дәрәҗәсенә

карата өстәмә рәвештә) торак пунктларыннан яңа яшәү урынына иркле рәвештә күченеп киткән гражданнар.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.»;

1.5-1.6 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

2-5 бүлекләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга (таныклык дубликаты) (алга таба – таныклык (таныклык дубликаты)) бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яисә шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) исеменнән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык, Идарә (бүлек)) тарафыннан күрсәтелә.

2.2.2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ), КФҮ ерактагы эш урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

Нәтиҗәне кәгазьдә теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

2.3.2. Мөрәҗәгать итүчегә таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү рәсмиләштерелә һәм мөрәҗәгать итүчегә үзе сайлап алган ысул буенча җибәрелә:

язма формада – почта адресы буенча;

электрон документ формасында электрон почта, мөрәҗәгать итүченең «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы»

дәүләт мәгълүмат системасындагы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) шәхси кабинетына җибәреп.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү таныклык (таныклык дубликаты) бирү турындагы гаризаны (алга таба – гариза) теркәгәннән соң 15 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында сорала торган белешмәләр булмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы гариза һәм документлар теркәлгәннән соң 20 эш көненә кадәр озайтыла.

2.4.2. Мөрәҗәгать итүчегә таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар Идарәгә (бүлеккә) алынган көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.3. Таныклык (таныклык дубликаты) һәм (яки) таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар күчермәсен таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында хәбәр ителгән мөрәҗәгать итүчегә тапшыру мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт граждан хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

## 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

таныклык алу өчен:

таныклык бирү турында гариза. Гаризаның тәкъдим ителә торган формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.

Әлеге Регламентның 1.2 пунктының «а», «в», «г» һәм «д» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә 3х4 см үлчәмендәге фотоны да тапшыралар.

Әлеге Регламентның 1.2 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга таныклыклар рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында Россия Федерациясенең Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм стихияле бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга таныклыклар рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында нигезләмә раслау турында» 2000 елның 24 апрелендәге 229 номерлы боерыгы (алга таба, тиешенчә – Россия ГТХ министрлыгы, Россия ГТХ министрлыгының 229 номерлы боерыгы, Россия ГТХ министрлыгының 229 номерлы боерыгы белән расланган Нигезләмә) белән расланган Нигезләмә нигезендә элегрәк бирелгән, вафат булган гражданин таныклыгы;

1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсе территориясендә һәлакәт һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысы нәтиҗәсендә гражданинның үлеменең сәбәпләрен билгеләү турында ведомствоара эксперт советы бәяләмәсе.

Таныклык дубликатын алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

таныклык дубликатын бирү турында таныклыкның югалу яки бозылу шартларын һәм беренчел документлар нигезендә аны алу урынын күрсәтеп гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән;

мөрәҗәгать итүченең 3 x 4 см үлчәмендәге фотосы (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы «а», «в», «г» һәм «д» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар өчен);

бозылган таныклык.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар өстәмә рәвештә үз вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен тапшыралар.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документтан белешмәләр Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасындагы (алга таба – ИАБС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, юридик зат тарафыннан бирелгән документ документны биргән вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, шәхси эшкуар тарафыннан бирелгән документ шәхси эшкуарның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, нотариус тарафыннан бирелгән документ нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш. Башка очракларда – гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алынырга мөмкин.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәгечә тапшырыла (җибәрелә) ала:

Идарәгә (бүлеккә) шәхсән яисә почта аша кәгазьдә җибәреп;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре (алга таба – «Интернет» челтәре) аша;

Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турындагы гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша биргән очракта, фото һәм бозылган таныклык (бозылганына алмашка таныклык дубликаты алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта) мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында кабул ителгән карар хакында белдерү алынганнан соң тапшырыла.

Документларның күчермәләре, әгәр дә алар законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гариза шулай ук Идарәдә (бүлектә) белгеч тарафыннан шәхсән кабул ителгәндә электрон рәвештә дә тутырылырга мөмкин, аңа мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон язуларны укый торган җайланмадан файдаланып имзалый.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырылган.http://mtsz.tatarstan.ru

Гаризаны һәм кирәкле документларны «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

2.6.3. Вәкаләтле органнардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында бирелә торган документлар (белешмәләр):

югалган таныклыкның табылмавын раслаучы белешмә (мөрәҗәгать итүче таныклыкның дубликатын сорап мөрәҗәгать иткән очракта);

Чиләбе, Свердловск, Курган өлкәләре башкарма хакимияте органнары тарафыннан бирелә торган бердәм үрнәктәге белешмә;

шәхси счетның иминият номеры турында.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрнераслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Югарыда аталган белешмәләрне үз эченә алган әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.

күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә) төп документларның күрсәтелмәве;

мөрәҗәгать итүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе;

документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларда булган белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булган очракта;

мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада тапшырылуы;

тапшырылган документларның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (шәхесне таныклый торган документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта).

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен ведомствоара багланышлар кысаларында сорала торган белешмәләрнең булмавы нигез булып тора.

2.8.2. Ялган (төгәл булмаган) белешмәләрдән торучы документларны тапшыру дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Документлар кабул ителгән көнне.

2.11.2. Идарәнең (бүлекнең) эш вакыты беткәч яки ял (бәйрәм) көнендә электрон формада килгән гариза икенче эш көнендә теркәлә.

## 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) Идарәнең (бүлекнең) хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте

күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

### 2.13. Дәүләт хезмәтенең сыйфаты һәм һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

Идарә (бүлек) хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәте күрсәтүгә комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе;

Идарә (бүлек) бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

Идарәнең (бүлекнең) мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү чорының саклануы;

Идарә (бүлек) белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән бәйләнешкә керү күләме:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлык сайтында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында алынырга мөмкин.

2.13.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) кабул ителгән карар турында электрон документ формасында хәбәр алырга;

е) Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Идарә (бүлек), шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гаризаны формалаштыру Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән формалаштырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында ИАБС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

2.14.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) җибәрелә. ИАБС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать

итүченең, гаризаны имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

2.14.5. Гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән кабул ителгән карар турында белдерү, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетка Идарә (бүлек) җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.14.6. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

2.14.7. Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

2.14.8. Мөрәҗәгать итүчеләрне Идарәгә (бүлеккә) кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Идарәнең (бүлекнең) телефон номеры аша телефон элемтәсе аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Идарәдә (бүлектә) билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итү көннәре, вакыты һәм урыннары.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Идарәнең (бүлекнең) телефон номеры буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

2.14.9. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.14.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

2.14.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә дә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны тутыру өлешендә дә;

2) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) белешмәләр алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм җибәрү;

4) таныклык (таныклык дубликаты) бирү турындагы үтенеч кәгазен Министрлыкка җибәрү;

5) таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

7) техник хатаны төзәтү.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, Мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат алу;

гариза формалаштыру;

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәүгә алу;

таныклык бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында белдерү алу;

гариза карау барышы турында мәгълүмат алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Идарә (бүлек) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) яисә Идарәнең (бүлекнең) вазыйфаи затлары яки дәүләт граждан хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү.

Гаризаны карау барышы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу, авторизацияләнү шарты белән, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетта гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта үз инициативасы буенча шәхси кабинетта электрон гаризаның статусын, шулай ук алга таба башкарылачак гамәлләр турында мәгълүмат карау мөмкинлегенә ия.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр җибәрелә:

а) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү  һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының башлану факты турындагы белешмәләрне, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүне тәмамлау датасы һәм вакыты турындагы белешмәләрне яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән нигезле баш тартуны үз эченә алган белдерү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре турында белдерү, анда дәүләт хезмәте күрсәтү турында кабул ителгән карар һәм таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар күчермәсен алу мөмкинлеге турында белешмәләр була.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, почта, электрон почта аша, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша һәм (яки) Идарәгә (бүлеккә) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Идарә (бүлек) белгече тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, консультация бирелә. Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бланкы бирелә һәм, кирәк булганда, мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән гаризаны тутыру өлешендә дә, ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша мөрәҗәгать иткән очракта, – мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне;

мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, почта һәм электрон почта аша мөрәҗәгать иткән очракта, –мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатен теркәгәннән соң 15 календарь көн узганчыга кадәр.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гаризаны тутыру өлешендә дә.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында гаризаны, әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларның күчермәләрен теркәп, Идарәгә (бүлеккә) тапшыра.

Идарәгә (бүлеккә) почта аша, электрон почта буенча, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алынган гариза мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителгән гариза һәм документларны карау өчен билгеләнгән тәртиптә карала.

Почта аша заказлы хат итеп яисә электрон формада җибәрелгән гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) гомуми тәртиптә карап тикшерелә.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизацияләү уза;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.2 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) гаризаның һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәләрен ясау һәм аларну саклау мөмкинлеге;

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

в) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

г) ИАБС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, ИАБС системасында урнаштырылган һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон гариза формасы кырларын тутыру;

д) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

е) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында бер елдан азрак булмаган чорда үзе элегрәк тапшырган гаризаларны, шулай ук кимендә 3 ай эчендә өлешчә формалаштырган гаризаларны карау мөмкинлеге.

Формалаштырылган һәм имзаланган гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Идарәгә (бүлеккә) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелә.

Идарә (бүлек) белгече өчен электрон гаризаны алу мөмкинлеге «Татарстан Республикасы Халыкның социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында тәэмин ителә.

Идарә (бүлек) белгече:

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан электрон гаризалар булу-булмавын көненә 2 тапкырдан ким булмаган ешлыкта тикшерә;

алынган гаризаларны һәм теркәлгән документлар рәвешләрен карый.

3.3.2. Идарә (бүлек) белгече дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм таныклыклар (таныклыкларның дубликатларын) бирү турында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы);

гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, алынганда беркетелгән номеры турында тамгалап, мөрәҗәгать итүчегә язу бирү – мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта;

гаризаны теркәү датасы һәм алынганда кергән номеры турындагы белдерүне җибәрү – гариза почта аша һәм (яки), Интернет челтәреннән файдаланып юлланган очракта;

гаризаны теркәү турындагы белдерүне Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрү – гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша биргән очракта, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Гаризаны һәм документларны почта аша һәм (яисә), Интернет челтәреннән алганда, Идарә (бүлек) белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә, – гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) кергән көнне;

гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яисә «Интернет» челтәре аша килгәндә, – гариза һәм докуметлар Идарәгә (бүлеккә) килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Идарәнең (бүлекнең) эш сәгате тәмамланган вакытта алынган очракта, аннан соңгы эш көнендә;

гариза һәм документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Идарәнең (бүлекнең) ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, таныклыклар (таныклыкларның дубликатларын) бирү турында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында гаризаны теркәү язуы, мөрәҗәгать итүчегә документларны алу кзгазе яисә кайтарып бирелгән документлар, документларны кабул итүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

3.4. Белешмәләр алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. Идарә (бүлек) белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәгеләрнең тапшырылуы турында вәкаләтле органнарга электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Чиләбе, Свердловск, Курган өлкәләре башкарма хакимияте органнары тарафыннан бирелә торган бердәм үрнәктәге белешмә;

эчке эшләр органнарыннан югалган таныклыкның табылмавын раслаучы белешмәләрне (мөрәҗәгать итүче таныклык дубликатын алу буенча мөрәҗәгать иткән очракта);

Россия Федерациясе Пенсия фондына – хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла. Документларны (белешмәләрне) тапшыру турында ведомствоара гаризага җавап әзерләү һәм җибәрү законнарда билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләрне һәм мәгълүматларны бирү турында рәсми мөрәҗәгать.

3.5. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турындагы үтенеч кәгазен Министрлыкка җибәрү.

3.5.1. Идарә (бүлек) белгече алынган, әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә законнарда билгеләнгән срокларда килгән белешмәләр нигезендә, шулай ук мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

таныклыкны (таныклык дубликатын) рәсмиләштерү өчен кирәкле документлар тупланмасы;

таныклык (таныклык дубликаты) бирүгә ведомость (алга таба – ведомость) проекты формалаштыра (ведомостьның формасы Россия ГТХ министрлыгының 229 номерлы боерыгы белән расланган Нигезләмәнең 4 нче кушымтасында китерелгән);

таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенеч проектын әзерли (алга таба– үтенеч);

Идарә (бүлек) җитәкчесенә кул кую өчен гариза һәм ведомость проектларын җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Документларны ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша сорату зарурлыгы булганда, – үтенечләргә җавап килгән көннән соңгы ике эш көне эчендә, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң җиде эш көненнән соңга калмыйча.

Процедура нәтиҗәсе: ведомство һәм үтенеч проектлары.

3.5.2. Документларны караганнан соң Идарә (бүлек) җитәкчесе үтенеч һәм ведомство проектларына кул куя.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: имзаланган үтенеч һәм ведомость.

3.5.3. Идарә (бүлек) белгече үтенечне һәм таныклык (таныклык дубликаты) рәсмиләштерү өчен кирәкле документларның күчермәләрен теркәп, ведомостьны Министрлыкка җибәрә.

Процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән үтенеч һәм таныклык (таныклык дубликаты) рәсмиләштерү өчен кирәкле документларны теркәп, ведомость.

3.6. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар кабул итү

3.6.1. Министрлыкның эшчәнлек башкару бүлеге белгече Идарәдән (бүлектән) килгән үтенечне һәм таныклыкны (таныклык дубликатын) рәсмиләштерү өчен кирәк булган документларның күчермәләре теркәлгән ведомостьны Татарстан Республикасының «Электрон Хөкүмәт» дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнеше системасында терки һәм Министрлыкның социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлегенә (алга таба – Бүлек) җибәрә.

Әлеге процедура Идарәдән (бүлектән) документлар Министрлыкка кергән көннән бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм Бүлеккә җибәрелгән үтенеч, документларның күчермәләрен теркәп, ведомость.

3.6.2. Бүлек белгече документларны Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучылар, Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнар таныклыкларын бирү (бирүдән баш тарту) турында карарларны әзерләү һәм документларны тикшерү һәм Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнар реестрына кертү (кертүдән баш тарту) комиссиясенә (алга таба – Комиссия) таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен документларны карау өчен җибәрә.

Әлеге процедура Идарәдән (бүлектән) документлар кергән көннән сигез эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Комиссиягә җибәрелгән документлар.

3.6.3. Комиссия башкара:

таныклыкны (таныклык дубликатын) рәсмиләштерү өчен кирәкле барлык документларның булуын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә җавап бирүен (документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган, өстәмә язулар өстәлгән, сүзләр сызылган һәм төзәтмәләр кертелгән урыннар булу-булмавын) тикшерә;

әлеге Регламентның 2.8 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуын тикшерә;

таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итә;

таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карарны имзалау өчен министр урынбасарына җибәрә;

таныклык (дубликат) бирү (бирүдән баш тарту) турында имзаланган карарны, документларны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документлар Бүлек белгече тарафыннан Комиссиягә җибәрелгән көннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Комиссия кабул иткән карар.

3.6.4. Бүлек белгече:

таныклык (таныклык дубликатын) бирүгә гариза (язма мөрәҗәгатьне) формалаштыра, Россия ГТХ министрлыгына гаризаны (язма мөрәҗәгатьне), министр урынбасары тарафыннан имзаланган, таныклык (таныклык дубликаты) бирү турындагы карарны, Россия Федерациясе законнары һәм Идарә (бүлек) тапшырган документлар күчермәләре нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәне китерә;

Комиссия таныклык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта, Идарәгә (бүлеккә) таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турындагы карар күчермәсен, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, җибәрә һәм документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Россия ГТХ министрлыгына җибәрелгән документлар, документларны Идарәгә (бүлеккә) кире кайтару.

3.6.5. Россия ГТХ министрлыгыннан таныклык бланкларын алганнан соң Бүлек белгече таныклык (таныклык дубликаты) балнкларын тутыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Россия ГТХ министрлыгыннан таныклык бланклары кергән көннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тутырылган таныклык (таныклык дубликаты) бланкы.

3.6.6. Бүлек белгече таныклык (таныклык дубликаты) бланкын министрга яисә аны алмаштыручы затка имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура таныклык (таныклык дубликаты) бланкын тутырганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзалау өчен җибәрелгән, тутырылган таныклык (таныклык дубликаты) бланкы.

3.6.7. Министр яисә аны алмаштыручы зат, таныклыкның (таныклык дубликатының) тутырылган бланкын имзалый, имзаны мөһер белән беркетә, таныклыкны (таныклык дубликатын) Бүлек белгеченә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр яисә аны алмаштыручы зат тарафыннан имзаланган, мөһер белән беркетелгән һәм Бүлек белгеченә тапшырылган таныклык (таныклык дубликаты).

3.6.8. Бүлек белгече:

таныклыкны теркәп, Идарәгә (бүлеккә) теркәү хаты проектын рәсмиләштерә;

Россия ГТХ министрлыгына таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту очрагында, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп һәм документларның күчермәләрен теркәп, таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында Идарәгә (бүлеккә) белдерү проектын рәсмиләштерә;

теркәлеп бара торган хатның һәм (яки) таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында белдерүнең проектларын имзалау өчен министр урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Министр яисә аны алмаштыра торган зат тарафыннан таныклык (таныклык дубликаты) имзаланган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәү хаты проекты, таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында белдерү проекты.

3.6.9. Министр урынбасары Идарәгә (бүлеккә) теркәү хатын яисә таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында белдерү проектын имзалый.

Процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган теркәлү хаты һәм (яки) таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында белдерү.

3.6.10. Министрлыкның эшчәнлек башкару бүлеге белгече Татарстан Республикасының «Электрон Хөкүмәт» дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнеше системасы аша имзаланган теркәү хатын яисә таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында имзаланган белдерүне, документларның күчермәләрен теркәп, терки һәм Идарәгә (бүлеккә) җибәрә һәм таныклыкны (таныклык дубликатын) Идарәгә (бүлеккә) җибәрә.

Процедура алдагы процедуралар тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарәгә (бүлеккә) җибәрелгән имзаланган теркәү хаты һәм (яки), документларның күчермәләрен теркәп, таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында кабул ителгән карар турында белдерү.

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.7.1. Министрлыктан документлар алынган очракта, Идарә (бүлек) белгече:

гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында белдерә;

мөрәҗәгать итүчене таныклык (таныклык дубликаты) алу өчен чакыра (почта адресы буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында җибәреп).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Министрлыктан таныклык (таныклык дубликаты) яисә таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында язма белдерү алынган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында белдерү, мөрәҗәгать итүчене таныклык (таныклык дубликаты) алу өчен чакыру.

3.7.2. Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә таныклыкны (таныклык дубликатын) Россия ГТХ министрлыгының 229 номерлы боерыгы белән расланган Нигезләмәгә 4 нче кушымтадагы форма буенча таныклыклар бирүне исәпкә алу исемлегендә имзалатып тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән таныклык (таныклык дубликаты).

3.8. Техник хатаны төзәтү

Элек бирелгән таныклыкта (таныклык дубликатында) җибәрелгән техник хаталарны бетерүгә бәйле рәвештә таныклыкны (таныклык дубликатын) яңадан рәсмиләштерү техник хатасы булган, Идарә (бүлек) белгече тарафыннан техник хатаны төзәтү турында гариза килгән көнне кабул ителгән һәм таныклыклар (таныклыкларның дубликатларын) бирү турында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәлгән таныклык (таныклык дубликаты) белән бергә тапшырылган гариза (киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.1. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турындагы үтенеч кәгазен Министрлыкка җибәрү

Идарә (бүлек) белгече гариза һәм техник хатасы булган таныклык (таныклык дубликаты) нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

ведомство проектын формалаштыра;

үтенеч проектын әзерли;

Идарә (бүлек) җитәкчесенә кул кую өчен үтенеч, ведомство проектларын җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: үтенеч һәм ведомство проектлары.

3.8.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе гаризаны һәм техник хатасы булган таныклыкны (таныклык дубликатын) караганнан соң, үтенечкә һәм ведомостька кул куя.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: имзаланган үтенеч һәм ведомость.

3.8.3. Идарә (бүлек) белгече Министрлыкка үтенеч, ведомость, техник хатасы булган таныклык (таныклыкның дубликаты) юллый.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән үтенеч, ведомость, техник хатасы булган таныклык (таныклыкның дубликаты).

3.8.4. Министрлыкның эш башкару бүлеге белгече Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Электрон Хөкүмәт» электрон документлар әйләнеше системасында Идарәдән (бүлектән) кергән үтенечне һәм ведомостьне терки һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Идарәдән (бүлектән) документлар кергән көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән ведомость, таныклык (таныклык дубликаты).

3.8.5. Алга таба административ процедуралар әлеге Регламентның 3.6.4 - 3.6.10, 3.7.1 - 3.7.2 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Регламент процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган идарәләрнең (бүлекләрнең) җитәкчеләре тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла. Контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы Идарәләр (бүлекләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламент (белешмәлек) кушымтасында китерелгән.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләргә тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итүне, җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

4.5. Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

4.6. Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.7. Әлеге Регламент үтәлешенә планнан тыш тикшерү уздыру турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.8. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, әлеге Регламентны үтәү өчен җаваплы булып, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.9. Әлеге Регламентның гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан үтәлешен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү барышында дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу белән идарә итү (бүлек) аша Министрлык эшчәнлегенең ачыклыгы аша башкарыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә Идарәнең (бүлекнең) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Идарә (бүлек) җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Идарә (бүлек) җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.

Министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче Идарә (бүлек), дәүләт хезмәте күрсәтүче Идарәнең (бүлекнең) вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан шикаять почтадан, күпфункцияле үзәктән, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mtsz.tatar.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче Идарәнең (бүлекнең), дәүләт хезмәтен күрсәтүче Идарәнең (бүлекнең) вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуын шикаять кылганда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган Идарәнең (бүлекнең) атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче Идарәнең (бүлекнең) вазыйфаи затының яки дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче Идарәнең (бүлекнең), дәүләт хезмәте күрсәтүче Идарәдәге (бүлектәге) вазыйфаи затның яисә дәүләт граждан хезмәткәренең

шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең Идарәнең (бүлекнең) яки дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәтен күрсәтүче Идарә (бүлек) тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, Мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.»;

әлеге Регламентка 1-4 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте

күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсенә (бүлегенә)
кая________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА

Дата: «____»____________ 20____ ел.

1.Мин, _______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)
яши торган адрес: ______________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)

| Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

Эш итү нигезе__________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эшләү вәкаләтен раслаучы документ реквизитлары)

Алучының СНИЛС ______________________________________________
Бирүегезне сорыйм______________________________________________________
(Алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (ышанычлы зат мөрәҗәгать иткән очракта тутырыла)

таныклык:______________________________________________________________
(1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү нәтиҗәләрен юкка чыгаруда катнашучы зат таныклыгы;

______________________________________________________________________________
«Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиоактив пычрануга дучар булган торак пунктлардан эвакуацияләнгән (күчерелгән) гражданин таныклыгы;

______________________________________________________________________________
нурланышның тупланган эффектив дозасын алган гражданин (7 сЗв (бэр) артык, ләкин 35 сЗв (бэр) артык түгел; 35 сЗв (бэр) артык)

______________________________________________________________________________

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

2. Гаризага түбәндәге документларны (күчермәләрне) һәм белешмәләрне терким:

| т/с | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

3. Тапшырылган белешмәләрнең төгәллеге, шулай ук кушып тапшырылган документларның хак булуы өчен җаваплы булам.
4. Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза.
әлеге адрес буенча язмача формада____________________________________
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресына ______________________________________
(электрон почта адресы)
«Татарстан Республикасы дәүләт һәм
муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы»
Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат
системасындагы шәхси кабинет аша ________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)
«__» __________ 20__ ел. Имза ______________________

Гариза һәм документлар кабул ителде
______ 20__ ел. _________ _____________________
(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

________________________________________________________________________

Аеру линиясе
Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры ________
Документлар саны ____ данә, __ биттә
Документларны кабул итте ____________ _________ ____________ _____ 20__ ел.
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

«1957 елда «Маяк» житештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә

елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта»

Киңәш ителә торган рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсенә (бүлегенә)

______________________________________
(муниципаль районында (шәһәр округында))

ГАРИЗА

«_____» ____________ 20_____ел.

1. Мин, ______________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
яши торган адрес: _____________________________________
(индексын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефоны, электрон почта адресы)
эш итү нигезе:_________________________________________________________
_______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклауны раслаучы документ реквизитлары)
Алучының СНИЛС ___________________________________________
Бирүегезне сорыйм(___________________________________________________)
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
(ышанычлы зат мөрәҗәгать иткән очракта тутырыла)
таныклык дубликаты _______________________________________________
(1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү нәтиҗәләрен юкка чыгаруда катнашучы зат таныклыгы;

_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________

«Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар әләгү аркасында радиоактив пычрануга дучар булган торак пунктлардан эвакуацияләнгән (күчерелгән) гражданин таныклыгы;

_______________________________________________________________________
____________________________________________________________________
_______________________________________________________________________

нурланышның тупланган эффектив дозасын алган гражданин (7 сЗв (бэр) артык, ләкин 35 сЗв (бэр) артык түгел; 35 сЗв (бэр) артык)

_______________________________________________________________

Элегрәк бирелгән таныклык алынган иде ____________________________

______________________________________________________________

(таныклык алу урыны)

Таныклыкны югалту (бозу) шартлары ____________________

2. Тапшырылган белешмәләрнең төгәллеге, шулай ук кушып тапшырылган документларның хак булуы өчен җаваплы булам.

3. Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза.

әлеге адрес буенча язмача формада______________________________

электрон документ формасында

электрон почта адресы буенча ______________________________

(электрон почта адресы)

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша _________________________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

«_____» 20__ел. Имза ____________________

Гариза һәм документлар кабул ителде _________________ _____ 20_____ ел.

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

_______________________________________________________________

Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү №_________

Документлар саны ____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте_________________________20_______ ел. ____

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

«1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Таныклыклар (таныклыклар дубликатлары) бирү турында гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналы

| № | Гаризаны кабул итеп алу датасы | Мөрә-җәгать итүче-нең ФИА | Мөрәҗә-гать итүченең адресы | Таныклык төре | Таныклык бирү турында белешмәләр | Социаль яклау органы белгече имзасы | Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы (хәбәр итү датасы) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

«1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар элгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсе (бүлеге) башлыгына
______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин,____________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)
яши торган адрес: _________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
____________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән органның аталышы)
техник хатаны төзәтүне сорыйм _______________________________________
______________ №________ таныклыкта (таныклык дубликатында) җибәрелгән,
бирелде _____________________________.
«_____» _____________ 20__ ел. _____________ ______________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)

3. Мәгълүмат, шул исәптән бирелгән таныклыкта (таныклык дубликатында) техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән карар турында мәгълүмат алуга(на) риза:

әлеге адрес буенча язмача формада____________________________________

электрон документ формасында

электрон почта адресы буенча ________________________________

(электрон почта адресы)

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша ____________________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

«_____» 20__ел. Имза ________________________________________

Гариза һәм документлар кабул ителде ____________________ 20_____ ел.

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

___

Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү №_________

Документлар саны ____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте________________________20_______ ел.

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларына аудит бүлеге җитәкчесе | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

2.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе җитәкчесе | 264-77-29 | pisma@tatar.ru». |